СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №144 (7443) | 3 декабрь 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## Күрсәткечләр яхшыра

Ульянов исемендәге колхоз терлекчеләре быелның ун аенда уртача һәр сыердан 2807 килограмм сөт саудылар. Бу узган елның шул чорындагыдан күбрәк. Колхозчылар терлекчелек продуктлары житештерү һәм дәүләткә сату буенча планнарын үтәү турында вәгъдәләренә тугрылыклы булып калалар.

Колхозда иң алдынгы сыер савучы Роза Билалова быел 11 айда һәр сыердан 3329 килограмм сөт савып алуга иреште. Савучы турында колхозда мактау сүзләренең иң олысын әйтәләр. Ул хезмәтен ихлас күңелдән башкара, фермага икенче туган йортына ашыккандай ашкынып килә. Чөнки нәкъ биредә ул зур хезмәт мәктәбе үтте, үз һөнәренең чын остасына әверелде. Сыерларны зооветеринария фәне кушканча карavы, рационда билгеләнгән азыкларны ашкәртеп, тәмләндереп ашатуы нәтиҗәсендә хезмәт күрсәткенләре дә куанычлы аның.

Ә маллардан мул продукция җитештерү өчен шартлар җитәрлек фермада. Биналар ремонтланган, җылы. Хезмәтнең күп өлеше механикалаштырылган. Савучылар да, малларга азык таратучылар да сыната торганнардан түгел. Кышлату чорында да маллардан продукция алуны киметмәү— аларның төп максаты.

**Н. МИҢҺАҖЕВА.**



## Ул алда бара

«Комбайн» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында бай тәҗрибә туплаган хатын-кызлар күп. Шулар арасында Әлфия Хуҗина турында гел җылы сүзләр генә әйтергә була. Әлфия намуслы, тырыш, ярдәмчел. Алдынгы тәҗрибәне өйрәнеп осталыгын күтәрергә омтыла, алган йөкләмәләрен арттырып үти. Ул агымдагы елның 10 аенда үзе караган һәр сыердан уртача 2706 килограмм сөт савып алды инде. Аның кабул итеп алган йөкләмәсен үтәвечә шик юк.

Әлфиянең тырышлыгына, үҗәтләнеп эшли белүенә иптәшләре дә сокланалар. Ул авырлыклар алдында баш иярга күнекмәгән, зарланырга яратмый. Шуңа да аны авыл халкы да ихтирам итә.

РӘСЕМДӘ: «Комбайн» колхозы сыер савучысы Ә. Г. Хуҗина.

Н. Азизов фотосы.

## Кырлар сый ала

«МАМЫК» СОВХОЗЫ. Хуҗалык игенчеләре басуларга өстәмә сый чыгаруга җитди игътибар бирәләр. Органик ашлама чыгару буенча районда игълан ителгән удар икеайлыкның беренче көннәреннән үк алар бу хезмәткә кушылдылар. Бүгенге көндә кырлар 3200 тонна өстәмә сый алдылар инде. Аны төяп торуда ДТ-75 тракторында төягеч белән Алексей Николаевич Гурьянов бик өлгер эшли.

Т-150 тракторчылары Виталий Николаевич Шмелев, Петр Кузьмич Афанасьев, МТЗ-80 дә Николай Иванович Михайлов, Сергей Васильевич Воспенников, Илья Николаевич Михайлов,-Николай Михайлович Васильев тиресне кырга ташуда бер өзеклек тә кичермәделәр.

Кырларны өстәмә ашлау дәвам итә.

**А. КОГТЕВ,**
экономист.

## Кем ничек эшли?

**Район хуҗалыкларында сөт җитештерүнең торышы.**

Беренче багана— хуҗалыклар исемнәре, икенче—1992 елның 1 декабрендә бер сыердан савылган сөт, өченче— узган елның шул чоры белән чагыштырганда артык яки ким.

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 5,7 | +0,1 |
| Ульянов исем. | 5,5 | +0,5 |
| «Правда» | 4,8 | +0,7 |
| «Восход» | 5,7 | +0,7 |
| Мичурин исем. | 9,0 | — |
| «Россия» | 7,7 | +2,1 |
| Хафизов исем. | 7,7 | +2,3 |
| «Путь к коммунизму» | 4,5 | —1,4 |
| Муса Җәлил исем. | 7,6 | +0,7 |
| «Родина» | 7,0 | +1,6 |
| «Игенче» | 5,8 | —0,4 |
| «Большевик» | 6,4 | +1,5 |
| «Заветы Ильича» | 5,7 | +1,7 |
| «Знамя Октября» | 4,2 | —0,8 |
| «Алга» | 4,2 | +0,5 |
| «Комбайн» | 6,0 | —0,1 |
| XXI партсъезд исем. | 4,9 | +0,4 |
| «Татарстан» | 8,3 | +1,9 |
| «40 лет Победы» | 5,5 | +0,9 |
| «Чишмә» | 3,4 | —0,9 |
| «Таң» | 5,4 | +1,7 |
| «Москва» | 5,4 | — |
| «Үрнәк» | 7,9 | +0,1 |
| «Кондырча» | 7,3 | +1,1 |
| Кузнецов исем. | 5,1 | —1,1 |
| «Заря» | 7,6 | —1,4 |
| «Чирмешән» | 6,9 | +0,7 |
| «Төрнәс» совхозы | 5,4 | +0,6 |
| «Мамык» совхозы | 5,2 | +0,7 |
| «Рассвет» совхозы | 8,7 | +0,1 |
| «Сөлчә» совхозы | 5,7 | +0,7 |
| «Беренче май» | 5,2 | +0,3 |
| «Яшь көч» | 6,8 | +2,6 |
| «Дуслык» | 6,0 | — |
| «Ленинский путь» | 13,3 | — |
| Район буенча | 6,0 | +0,6 |

## КАЙДА НӘРСӘ НИЧЕК

Россиянең яңа иҗтимагый оешмасы—югары уку йортлары ректорлары берлеге Союзлар йортының Колонналы залына үзенең съездына җыелды. Аның эшендә Борис Ельцин да катнашты. Һәм вузларга җирне һәм төп фондларны бушлай куллану турындагы указга кул куюын хәбәр итте.

⊙

Американың Эй-би-си телекомпаниясенең 1989 елда баткан «Комсомолец» атом су асты көймәсенең Норвегиядә яшәүчеләргә зур куркыныч тудыруы турындагы хәбәре әлегә илдә зур шау-шу тудырды. Ләкин Норвегия белгечләре әлегә «Комсомолец» бернинди куркынычка урын калдырмый дип саныйлар.

⊙

Карачай шахта идарәсенең бер шахтасында (Ставрополь крае) зур авария булды. Метан газы шартлау нәтиҗәсендә шахтада эшләүче 18 кешенең 8е һәлак булды, 5се авыр җәрәхәт алды. Калганнарының язмышы әлегә билгесез.

⊙

Израильгә рәсми визит белән Франция Президенты Франсуа Миттеран килде. Бу визитны Израильнең премьер-министры Ицхак Рабин ике ил арасындагы мөгамәләләрдә яңа бүлек, дип саный. Миттеран белән бергә 200 ләп министр, эшкуар да бар.

⊙

Литва Сеймының рәисе итеп яңа гына сайлауларда җиңеп чыккан Литва хезмәт демократик партиясе лидеры Альгирдас Бразаускас сайланды. Ул хәзер вакытлыча илнең Президенты вазифаларын да башкара.

⊙

Кытай тарихында иң зур авиакатастрофа булды. Бортында 141 пассажир булган «Боинг-737» самолеты һәлакәткә очрады. Экипаж һәм пассажирларның барысы да (алар арасында Канада һәм Тайвань гражданнары да булган) һәлак булды.

⊙

Румын диктаторы Николае Чаушеску улы Ника Чаушеску сәламәтлеге начараюы сәбәпле төрмәдән чыгарылды. Хәзер аңа 41 яшь. Ул тыныч демонстрациячеләрне атуны оештыруда гаепләнә.

⊙

Беларусь хөкүмәте беренче эчке дәүләт заемын чыгару турында карар кабул итте. Ул 490 миллион сум тәшкил итәчәк. Заем киләсе елдан гамәлгә керә.

*Безнең рейд*

## Никадәр тизрәк—шулкадәр файдалырак

«Сельхозтехника» район берләшмәсе гомер-гомергә авыл эшчәннәренә техниканы сафка бастыруда, аның гомерен озайтуда төп булышчы булды. Быел да җәйге-көзгә эшләр тәмамланып, ремонт мәшәкатьләре башлануга берләшмәгә колхоз-совхозлардан техника килә башлады.

**Укучыга белешмә өчен: «Сельхозтехника»ның район берләшмәсе төп промышленность продукциясе җитештерү ягыннан башка район берләшмәләре белән бер дәрәҗәдә диярлек бара. Биредә тракторлар, бөртек комбайннары һәм аларның узелларын, агрегатларын ремонтлау, дизель двигательләрен, үзйөрешле азык җыю, силос җыю комбайннарын ремонтлау, иске детальләрне торгызу, трактор һәм машиналарны, терлекчелек фермалары машиналарын һәм җиһазларын техник карау кебек эшләр башкарыла. Моннан тыш берләшмә бурычына автотранспорт, таккычлы трактор белән йөк ташу, материаль-техник средстволарны реализацияләү дә керә.**

—Һәр елның үз кыенлыгы була инде,—ди берләшмә управляющие А. Т. Воронцов, эшләрнең ничек баруы белән кызыксынуыбызга җавап итеп.

—Быел, мәсәлән, финанс кулдан нык тота. Керем юк, лимит юк. Бүген, мәсәлән, колхоз-совхозлар безгә 38 миллион сум тиеш булсалар,без үзебез төрле оешмаларга 104 миллион сум бурычлы.

Ярлылык, әлбәттә, берләшмәнең теге яки бу дәрәҗәдә үтенеч белән сөйләшү алып бару мөмкинлекләрен нык чикли. Нәтиҗәдә запас частьләргә, инструментларга кытлык туа. Управляющийның кислород, коленвал, резина, шәмнәр юк дип җитешмәгән дефицитлар санавына цех, мастерскойларны үткәч, янә бер инандык, ул исемлекнең тагы да артуын күрү генә сөендермәде. Әйтик, Т-70С тракторына пешкәк группасы, НШ-10, НШ-32 насослары, техниканың йөрү өлешен ремонтлау өчен подшипниклар, тыгызлау чехоллары, шайбалар, реставрацияләү өчен юнәлеш тәгәрмәче җитешмәүгә зарландылар, комбайннар ремонтлау цехында инструментлар, наждак боҗралары, кыстыргычлар, комбайн узелларын ремонтлау өчен аерым төр вариаторларга подшипниклар, җиһазлар төзәтергә клапаннар, гидроусилительләр боҗралары, цилиндрга резина боҗралар, пешкәк саплары һәм башкаларга кытлык зур икәнлеге мәгълүм булды. Элек моның ише мәсьәләләрне хәл итү күпкә җиңелрәк булган, чөнки тәэминат базасы берләшмәнең үзендә иде. Инде «Агроснаб» базасы мөстәкыйльлеккә чыккач, аның төп вазифасы колхоз-совхозларны тәэмин итү

(Башы. Ахыры 2 нче биттә).

